ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 10 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтаның 2 пунктына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктчада:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«транспорт чараларына тыгызландырылган (кысылган) һәм (яисә) сыекландырылган табигый газ (метан) салу мөмкинлеген тәэмин итә торган гавами файдаланудагы стационар автомобиль ягулык салу станциясе (тыгызландырылган (кысылган) һәм (яисә) сыекландырылган табигый газ (метан) салу мөмкинлеген тәэмин итә торган катнаш ягулык автомобиль ягулык салу станциясе, автомобиль газ тутыру компрессор станциясе, тыгызландырылган (кысылган) һәм (яисә) сыекландырылган табигый газ (метан) салу мөмкинлеген тәэмин итә торган криоген автомобиль ягулык салу станциясе) төзелешенә кимендә 70 миллион сум;»;

б) өченче – алтынчы абзацларны тиешенчә дүртенче – җиденче абзацлар дип санарга;

2) 5 пунктчаның дүртенче абзацында «Төзүчеләрнең бөлгенлеге (банкротлыгы) вакытында өлешле төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания турында һәм» сүзләрен «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компания турында һәм» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                  Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 25 февраль
№ 4-ТРЗ